Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел № 2

Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 12 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 02-08-01/168 номерлы протестын карап

Миңлебай авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 12 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Миңлебай авылы,Ш.Бикчурин урамы, 50 йорт, Миңлебай станциясе, Шоссейная урамы, 20А йорт торак пункт территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Миңлебай авыл башкарма
комитеты җитәкчесе И.М. Рәхимов